ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Татарстан Республикасы документларының мәҗбүри нөсхәсе турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 26 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы документларының мәҗбүри нөсхәсе турында” 2005 елның 18 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш); 2016, № 7 – 8) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның бишенче абзацында “тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләрне башкаручы оешмалар,” сүзләреннән соң “базаларында фәннәр кандидаты гыйльми дәрәҗәсе, фәннәр докторы гыйльми дәрәҗәсе алу өчен диссертацияләр яклау советлары булдырылган оешмалар,” сүзләрен өстәргә;

2) 4 статьяда:
а) өченче абзацта “исәпкә алуны” сүзләреннән соң “һәм статистик исәпкә алуны” сүзләрен өстәргә;
б) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
“бөтендөнья фәне һәм техникасы казанышлары турында җәмгыятькә хәбәр итү.”;
в) түбәндәге эчтәлекле өлеш өстәргә:
“Электрон рәвештәге басманың мәҗбүри нөсхәсеннән һәм электрон рәвештәге диссертациянең мәҗбүри нөсхәсеннән файдалану Россия Федерациясе Граждан кодексы таләпләре нигезендә гамәлгә ашырыла.”;

3) 5 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“5 статья. **Татарстан Республикасы документларының мәҗбүри нөсхәсе составына керә торган документлар төрләре**

Татарстан Республикасы документларының мәҗбүри нөсхәсе составына түбәндәге төр документлар керә:

басмалар (текст, нота, картографик, сынлы сәнгать басмалары) – редакцияләү-нәшерлек эшкәртүен узган, полиграфик яктан мөстәкыйль бизәлгән, бастырып чыгару белешмәләре булган басмалар;

электрон рәвештәге басманың нөсхәсе – текстын, иллюстрацияләрне һәм бизәүнең барлык элементларын кертеп, бастырылган документтагы (басмадагы) мәгълүматны күчереп яздыра торган һәм документ аннан бастырыла торган оригинал-макетның электрон күчермәсе;

сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен басмалар – Брайль системасы буенча рельеф-нокта шрифты белән әзерләнә торган басмалар, рельеф-график басмалар, “сөйли торган китаплар”, начар күрүчеләр өчен эре шрифтлы басмалар, сукырлар өчен электрон басмалар (Брайль дисплее һәм сөйләм синтезаторы ярдәмендә күрүләре зәгыйфьләнгән кешеләр уку өчен яраклаштырылган басмалар);

рәсми документлар – Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары кабул иткән һәм алар тарафыннан яисә аларның исеменнән бастырып чыгарылган документлар;

аудиовизуаль продукция – теләсә кайсы төрдәге саклагычларда барлыкка китерелгән һәм күчереп яздырылган кино-, видео-, фоно-, фотопродукция һәм аның комбинацияләре;

электрон басмалар – мәгълүмат электрон-цифрлы рәвештә бирелгән һәм редакцияләү-нәшерлек эшкәртүен узган, бастырып чыгару белешмәләре булган, электрон укылышлы саклагычларда ишәйтелә һәм таратыла торган документлар;

бастырып чыгарылмаган документлар – фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эш нәтиҗәләрен тәшкил итүче документлар (диссертацияләр, фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләр турында хисаплар, депозитланган фәнни эшләр, алгоритмнар һәм программалар);

патент документлары – сәнәгать милке объектларына патентлар һәм заявкалар тасвирламалары;

электрон хисаплау машиналары өчен программалар һәм матди саклагычтагы мәгълүмат базалары;

илкүләм стандартлаштыру системасында эшләнә һәм кулланыла торган документлар, гомумроссия техник-икътисадый һәм социаль мәгълүмат классификаторлары, кагыйдәләр җыентыклары;

катнаш документлар – төрле саклагычларда (басма, аудиовизуаль, электрон) эшләнгән документлар җыелмасы.”;

4) 7 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“7 статья. **Татарстан Республикасы документларының мәҗбүри нөсхәсен илтеп җиткерү**

Документлар җитештерүчеләр, шул исәптән полиграфия оешмалары аша, түбәндәгеләрне илтеп җиткерәләр:

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенә Татарстан Республикасы документларының мәҗбүри нөсхәсе составына керә торган барлык төр

документларның өчәр мәҗбүри нөсхәсен, моңа электрон рәвештәге басманың нөсхәсе керми;

Татарстан Республикасы Дәүләт матбугат архивына барлык төр басмаларның берәр мәҗбүри нөсхәсен;

Татарстан Республикасы Дәүләт үзәк аудиовизуаль документлар архивына аудиовизуаль продукциянең берәр мәҗбүри нөсхәсен.

Документлар җитештерүчеләр мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып, электрон рәвештәге басмаларның документ җитештерүченең квалификацияләнгән электрон имзасы белән таныкланган берәр мәҗбүри нөсхәсен Татарстан Республикасы Милли китапханәсенә илтеп җиткерәләр.

Документларның мәҗбүри нөсхәләрен илтеп җиткерү сроклары һәм тәртибе Татарстан Республикасы документларының мәҗбүри нөсхәсе составына керә торган тиешле документлар төрләренә карата “Документларның мәҗбүри нөсхәсе турында” Федераль закон нигезендә билгеләнә.”;

5) 9 статьяның беренче абзацында “аны теркәү һәм исәпкә алу” сүзләрен “аны теркәү, дәүләт библиографик исәпкә алу һәм статистик исәпкә алу” сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2017 ел, 11 гыйнвар
№ 2-ТРЗ